“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# Чишмә башы

№ 6
Апрель

Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит

## Апрель ае – табигатьнең яшәрүе, җир анабызның уянуы

Хәзер инде кар көннән-көн кими. Көпшәк кар астында су җыела, урыны-урыны белән кар өстеннән каралып язгы ташу акканы күренә. Ул үзенә бертөрле гүләү белән килеп төшә. Юлында очраган барлык нәрсәне үзе белән алып китә. Елгада бозлар кузгала. Зур-зур бозларның агып киткәнен карап торуы нинди күңелле! Кояш иртәрәк карый торган яр буйларында, юка бозны тишеп, зәңгәрсу умырзаялар чыга. Аларның оя-оя булып утырулары күңелләрне нечкәртә. Йонлач сабакларына, матур чәчәкләренә карап сокланып торасың. Тиздән сап-сары тузганаклар да күренә башлар. Җир йокыдан уяна. Зәңгәр күктә язгы кояш елмая. Җылы яклардан, туган якларын сагынып, яз хәбәрчеләре – каргалар, сыерчыклар кайта. Урамда иртәдән кичкә кадәр балаларның шат тавышы ишетелә. Күңелле дә соң яз көне!

## Табигатьне саклау- безнең изге бурычыбыз

Без - табигать балалары:
Уллары һәм кызлары.
Саклыйк әле табигатьне!
Саклыйк әле Җир шарын!

Табигать ул - безнең туган йортыбыз, ул - яшәеш чыганагы. Шуңа күрә аны саклау – һәркемнең изге бурычы.Бүгенге көндә табигатьне саклау, балаларга экологик тәрбия бирү безнең бурычыбызның берсе булып тора.Менә шуның өчен бөтен көчебезне экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерергә тиешбез. Шул уңайдан бакчабызда әти-әниләр ярдәме белән бик күп эшләр эшләнде: кызыклы чаралар үткәрелде, макулатура җыелды, сыерчык оялары ясап эленде, агачлар утыртылды, әйләнә—тирәбез җыештырылды.







# Апрель ае – бөек шагыйребезнең туган ае, шигърият ае



Халкыбызның зур байлыгы, кадерле рухи хәзинәсе — аның теле. Безнең телебез — татар теле. Зур тарихлы, бай, җырлы — моңлы тел.

Татар теленә мәхаббәт уяту ул әлбәттә гаиләдән һәм балалар бакчасыннан башлана. Туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияләү, телебезне саклау Г.Тукай иҗатын өйрәнүдән башлана. Ә апрель аенда, татар халкының бөек шагыйре, йөзек кашы туган айда бу чаралар аеруча да үзенчәлекле уза.
Балалар тәрбияче апалары белән берлектә Габдулла Тукайның экиятләре, шигырьләре белән танышалар, мультфильмнарын карыйлар. Төрле рәсемнәр ясап әти — әниләрен сөендерәләр. Ә йомгаклау чарасы — Габдулла Тукайга багышланган әдәби — музыкаль кичә булып узды. Бакчабызда тәрбияләнүче икенче зурлар төркеме балалары “Без Тукай шәкертләре” дип исемләнгән музыкаль тамаша әзерләделәр. Бәйрәмдә балалар өйрәнгән шигырьләрен сөйләделәр, “Кәҗә белән сарык” әкиятен сәхнәләштерделәр. Музыкаль кичә җырлар, уеннар белән үрелеп барылды. Бу чарадан әти — әниләр дә читтә калмадылар. Балалары белән бергә Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр ясап эшләп килделәр. Шушы эшләнмәләрдән бакчабызда күргәзмә дә оештырдык. Газиз, кадерле татар телебезне үзебез дә, балаларыбыз да сакласак иде. Үз туган телебездә аралашып яшәргә язсын.

## "Тукай безнең күңелләрдә” дип исемләнгән шигырь укучылар бәйгесе



Шигырь укучылар бер-берсеннән башкару осталыгы ягыннан аерылып торсалар да, шунысы бәхәссез, алар барысы да үзләренең хисләрен тамашачыга җиткерергә тырышты.
Алар сөекле шагыйребезнең шигырьләрен яттан сөйләп иҗади осталыкларын күрсәттеләр, мәртәбәле жюри тарафыннан бәяләнделәр. Барлык катнашучыларга җиңүче дипломы һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. Тукайны сөюче, туган телен яратучы, хөрмәт итүче балалар булганда гына телебезнең, илебезнең киләчәге өметле булыр.

## “Туган телем – иркә гөлем” район күләмендә шигырь укучылар бәйгесе



Бүген, 29 нчы апрель көнне, Арча шәһәренең 1 нче балалар бакчасында “Туган телем – иркә гөлем” дип исемләнгән район күләмендә шигырь уку бәйгесе узды.
Чарада барлыгы 3 яшьтән 7 яшькә кадәр булган 39 бала катнашты.

Бәйгенең бурычлары: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда татар теленә, татар язучыларының иҗатына, мәдәниятенә һәм гореф-гадәтләренә мәхәббәт һәм әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү; балаларны нәфис сүз осталыгына җәлеп итү; аларда сәнгатьле сөйләм, уку һәм башкару осталыгы күнекмәләрен формалаштыру; мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында талантлы башкаручыларны ачыклау.
Шигырь укучылар бер-берсеннән башкару осталыгы ягыннан аерылып торсалар да, шунысы бәхәссез, алар барысы да үзләренең хисләрен тамашачыга җиткерергә тырышты.

Аларның чыгышын мөхтәрәм жюри әгъзалары бәяләде:
Ветеран укытучы, Арча үзәк китапханәсе каршында эшләп килүче “Каурый каләм” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, күп санлы сценарийлар авторы, һәвәскәр шагыйрә Халидә Абдулхаковна Файзрахманова;
Ветеран тәрбияче, күп еллар балаларга татар телендә тәрбия бирүче һәм туган телне өйрәтүче хөрмәткә лаек Фәния Миннегалиевна Солтанова;
Арча мәгариф идарәсенең милли мәгариф эшләре буенча методисты Энҗе Габдуллатҗановна Мостафина;
Арча мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү буенча методисты Алинә Радиковна Имманаева.
Бер баланың да чыгышы игътибарсыз калмады. Барлык катнашучыларга грамоталар һәм мәгариф идарәсенең истәлекле бүләкләре тапшырылды.



Бакчабызда тәрбияләнүче кечкенәләр төркеменнән Хабибуллин Аяз һәм мәктәпкә әзерлек төркеменнән Габдрахманова Аделя 1 нче урынга лаек булдылар. Котлыйбыз аларны!

## Безнең уңышларыбыз

**Ахметгалиев Азамат**
**«Стихи рожденные войной»**
**дип аталган**
**Республикакүләм конкурста**
**3 нче урын**



**“Радуга талантов» дип исемләнгән балалар фестивалендә**
**Абраров Әмир 1 нче урын,**
**Шакуров Даян 2 нче урын**





Зурлар төркеме балалары арасында **" Без - табигатьнең дуслары! "** дигән викторина булып узды. Бәйрәмгә кунакка Ау бабай һәм Су анасы килде. Бәйрәмнең махсус кунаклары Биоресурслар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының "Ашыт" табигый тыюлыгы белгечләре Әхмәтҗанов Рәшит Зиннур улына һәм Мөхәммәтҗанова Аделина Рамиль кызына да бәйрәм бик ошады. Алар балаларга махсус бүләкләрен тапшырдылар, табигатьне сакларга кирәклеген тагын бер кат искәртеп уздыралар.



**“Юл билгеләре иленә сәяхәт “**

Соңгы елларда юлларда транспорт саны арткананнан арта бара. Бу исә юлларда бик сак йөрергә кирәклеген искәртә. Балаларыбыз исән-имин йөрсеннәр өчен, иң кирәкле һәм гади юл йөрү кагыйдәләрен балалар бакчасыннан ук белергә тиеш.

Бүген без 1 номерлы балалар бакчасына йөрүче мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән” Юл билгеләре иленә сәяхәт”дигән темага күңел ачу кичәсе үткәрдек.

Бәйрәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен белергә теләүче кунаклар килүе белән башланып китте. Балалар аларга юлда үзеңне ничек тотарга кирәклеген бик теләп сөйләделәр, юл билгеләренең нәрсә аңлатканын күрсәттеләр.



“Юл билгеләре илендә”балаларны ЮХИДИ хезмәткәре каршы алды.Ул балаларның белемнәрен тикшерде.

Кичәнең кунагы Арча районының профилактика мөдире Мөхәммәтҗанова Энҗе Газиз кызы да килгән иде. Ул аларга бүләкләр тапшырды. Балалар бу кичәдә бик теләп катнаштылар һәм канәгать калдылар. Аларга белемнәре киләчәктә дә кирәк булыр дип ышанып калабыз. Юл уяуларны, сак булганнарны ярата. Моны беркайчан да истән чыгармыйк. Адымнарыбыз нык, юллар имин булсын!